СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гагарина, д.29, с.Куюк-Ерыкса,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Гагарин ур., 29 нче йорт, Көек-Ерыкса авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-66-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР РЕШЕНИЕ

25.03. 2025 ел № 1-43

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 34 статьясының 7 пункты нигезендә Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәте белән бергә, 2025 елнын 28 мартыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (mamadysh.tatarstan.ru) юлы белән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек-Ерыкса авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

1.Көек Ерыкса авылы, Гагарин урамы, 29 йортта урнашкан Көек Ерыкса мәдәният йорты бинасы
2. Көек Ерыкса авылы, 1 Май урамы, 45 нче йортта урнашкан кибет бинасы
3.Яңа Комазан авылы, Вахитов урамы,16 нчы йортта урнашкан кибет бинасы
4.Малмыжка авылы, Совет урамы, 28 нче йортта урнашкан Малмыжка мәдәният йорты бинасы

5.Зур Шыя авылы, Давыдов урамы, 43 нче йортта урнашкан Зур Шыя авыл клубы бинасы
6.Гришкин авылы, Кызыл Байрак урамы, 23б нче йортында урнашкан Гришкин авыл клубы бинасы

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Көек-Ерыкса
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе /Ф.Р.Шәйхетдинов/

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советының 25.03.2025 ел, №1-43 карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 102.

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Көек-Ерыкса авылы – Гагарин урамы 1-32, 1 Май урамы 2-8, 11-37 (так) номерлы йортлар.

**2 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 97

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Көек-Ерыкса авылы - Яшьлек урамы, Гагарин урамы 33-62, 1 Май урамы 39-73 (так) нче йортлар.

**3 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 108

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Көек-Ерыкса авылы - 1 Май урамы 10-98 (так), 100-104, Баллы Чишмә урамы 10, Нaратлы урамы 17-37 номерлы йортлар.

**4 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 111

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Көек-Ерыкса авылы - Наратлы урамы 1-12, Баллы Чишмә урамы 1-9,11, Яңа Комазан авылы – Сахалин авылы, Габдулла Тукай урамы, Баллы Чишмә урамы 11,13,15, Кооперативлы урамы 1-23 (так) номерлы йортлары.

**5 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны -111

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Яңа Комазан авылы – Вахитов урамы 1-27,31, 34-45,49-57(так), Баллы Чишмә урамы 1-7,12,14, Кооперативлы урамы 2-22 (җөп) нче йортлар.

**6 нчы Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы.**

Сайлаучылар саны -99

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Яңа Комазан авылы - Муса Җәлил урамы, Вахитов урамы 28,30,32,46-58 (так), Хутор урамы, Иске Черкас авылы- Кояшлы урамы 1-16,22,26 нчы йортлар.

**7 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны -106

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Гришкин авылы, Яңа Черкас авылы, Иске Черкас авылы – Кояшлы урамы 17,23-25 нче йортлар.

**8 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны -101

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Зур Шыя авылы – Давыдов урамы 51- 105(так),50-104(җөп) нче йортлар керә.

**9 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны -106

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Каргалы авылы, Зур Шыя авылы - Давыдов урамы 1-49(так),4-48(җөп) нче йортлар керә.

**10 нче Көек-Ерыкса бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 104

Округка Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә Малмыжка авылы, Яковка авылы, Сотый поселогындагы йортлар керә.

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте

